ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 6 июнендә
кабул ителде

## 1 статья

«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 8; 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 1 – 2, № 4, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 20 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяның 2 пунктында:

а) беренче абзацта «дини оешманы дәүләт теркәвенә алу хакындагы карарны кабул итәргә вәкаләтле органга» сүзләрен «дини оешманы дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының Татарстан Республикасында территориаль органына» сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче абзацта «дини оешманы дәүләт теркәвенә алу турында карар кабул итәргә вәкаләтле органга» сүзләрен «дини оешманы дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының Татарстан Республикасында территориаль органына» сүзләренә алмаштырырга;

2) 15 статьяда:

а) 4 пунктта «федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы» сүзләрен «дини оешманы дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

б) 5 пунктта «федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы» сүзләрен «дини оешманы дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма

хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

2) 30 статьяда:

а) 3 пунктта «суд тәртибендә бетерелергә мөмкин» сүзләрен «дини оешманы дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы яисә аның Татарстан Республикасында территориаль органы таләбе буенча суд тәртибендә бетерелергә тиеш» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 пунктның беренче абзацында «теркәүче орган» сүзләрен «дини оешманы дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы яисә аның Татарстан Республикасында территориаль органы» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 18 июнь
№ 44-ТРЗ